| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>КУГУШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КҮГЕШ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**31 январь 2025 ел** Күгеш авылы **№3**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгеш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «2025 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 23 гыйнварындагы 33 номерлы карары нигезендә Башкарма комитет Күгеш авыл җирлеге

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2025 елның 01 февраленнән Зеленодольск муниципаль районының Күгеш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 9 165,37 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгеш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2024 елның 02 февралендәге 2 номерлы карарын 2025 елның 01 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә һәм җирлекнең Күгеш авылы, мәктәп яны урамы, 1а Йортындагы мәгълүмат стендларында (җирлек администрациясе бинасы).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 01.02.2025 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Күгеш авыл җирлеге башлыгы:** **А.А.Гатауллин**

1 нче кушымта
карарга Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге башкарма комитеты
2025 елның 31 гыйнварындагы 3 номерлы

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгеш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 01.02.2025

| **Хезмәтләр атамасы** | **Хезмәтләр бәясе (сумга)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Каберне һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 4 994,68 |
| 3. Үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка ташу | 1 422,81 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 2 747,88 |
| **Барлыгы** | **9 165,37** |

2 нче кушымта


карарга Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге башкарма комитеты
2025 елның 31 гыйнварындагы 3 номерлы

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгеш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе 01.02.2025

| **Хезмәтләр атамасы** | **Хезмәтләр бәясе (сумга)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Тәннең киеме | 882,44 |
| 3. Каберне һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 4 112,25 |
| 4. Үлгән кешенең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка ташу | 1 422,81 |
| 5. Күмү (кабер казу һәм күмү ) | 2 747,87 |
| **Барлыгы** | **9 165,37** |